КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1097

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында тискәре метеорологик шартлар чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруны җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 ел, 22 май, 407 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 апрель, 354 нче; 2021 ел, 21 гыйнвар, 18 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

сигезенче абзацта «экология күзәтчелегендә» сүзләрен «экология контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «Учреждение күзәтүенә алынган торак пунктларда урнашкан» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктның өченче абзацында «экология күзәтчелегендә» сүзләрен «экология контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин